ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында” Татарстан Республикасы Законының $4^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында” 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $4^1$ статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 1), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“2. Муниципаль норматив хокукый актта Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына каршы килә торган нигезләмәләр ачыкланганда, вәкаләтле органның эксперт бәяләмәсе, аны төзегән көннән алып җиде эш көне эчендә, мондый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органына (җирле үзидарәнең вазыйфаи затына), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм прокуратура органнарына җибәрелә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 66-ТРЗ